**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№16** **«28» декабрь 2020 ел.**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 123 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 200 3елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасынд ахайваннар белән эш итү өлкәсендәг еаерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезенд, Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 12 декабрендәге 124 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сосновский балтырганы– эре үлән үсемлек, зонтиклылар семьялыгының төре. Үсемлекнең көчле һәм озак төзәлми торган пешкән сыман җәрәхәт барлыкка китерү сәләте бар;»;

1.2. 9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Җир кишәрлекләре хуҗалары милек хокукында булган җир кишәрлекләреннән Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар күрергә тиеш. Сосновский балтырганын бетерү чаралары үсемлек чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк атканчы үткәрелергә тиеш.»;

1.3. 175 пунктта«Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 07 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә

тиеш.» дигән икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU),Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең рәсми сайтында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **Т.В.Попова**